**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Нырты авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**10 ноябрь 2022 ел** **№ 6**

**«Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты совхозы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 23 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Нырты авылы, Мәктәп урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 23 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Нырты авылы, Мәктәп урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

3. 2022 елның 25 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Нырты авылы, Мәктәп урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

4. 2022 елның 25 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Нырты авылы, Мәктәп урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан (курсантлардан), I төркем инвалидларыннан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Нырты авылында урамындагы юлларга вак таш җәю (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- Җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү)

- Кыш көне Нырты авылы юлларын кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- Нырты авылында урам яктыртуны тәэмин итү (энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү);
- Су белән тәэмин итү ситсемасын төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу);
- Нырты авылы территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);
- Видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру (смета төзү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (смета төзү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, янгынга каршы җиһазларны сатып алу, урнаштыру);
- Спорт мәйданчыгын һәм һәйкәлне карап тору (смета төзү, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Артезиан скважинасы өчен насос сатып алу һәм урнаштыру (техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»»?

7. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Нырты авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Нырты авыл җирлеге башлыгы: Т.А.Котдусов

ОГРН 1021607754563
ИНН 1623001710